**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Ятмас-Дусай авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2020 елның 13 ноябре** **N13**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 29 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыененың беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ятмас Дусай авылы, Үзәк урамы, 73а йорт адресы буенча урнашкан Ятмас Дусай авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 30 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыененың икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ятмас Дусай авылы, Үзәк урамы, 73а йорт адресы буенча урнашкан Ятмас Дусай авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ятмас Дусай авылында, вак таш җәеп, Үзәк урамындагы юллардагы чокырларны ямау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Ятмас Дусай авылының Үзәк урамына янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- торак пунктка керү һәм чыгу юлында видеокамералар урнаштыру;
- Ятмас-Дусай авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Ятмас Дусай авылында кышын юлларны карап тоту, кардан чистарту;
- чишмә территориясен төзекләндерү ?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы: Ф. Х. Гарифуллина